ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2021 М ө с л и м 106

**«Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 августындагы 518 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**
**(25.02.2021 ел редакциясендә)**

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына кертелгән түләүләр йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия Беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 сентябрендәге 1140 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына туры китереп, Мөслим муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 августындагы 518 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3.4.1 пунктын түбәндәге пунктча белән тулыландырырга: «3) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр».**

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**